ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**01.02.2023**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 167**

«2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 15 ноябрендәге 3140 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1601 статьясындагы 32 пунктының дүртенче абзацы нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген раслау турында» 2022 елның 15 ноябрендәге 3140 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган 2023 елга һәм 2024, 2025 еллар план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә (2022 елның 27 декабрендәге 3553 номерлы, 2023 елның 16 гыйнварындагы 30 номерлы карардагы үзгәрешләр белән).(алга таба - Исемлек) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Исемлеккә түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «802 | 116 11064 01 0000 140 | Авыр йөкләр һәм (яки) зур габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына китерелә торган зыянны каплау максатларында түләнә торган түләүләр» |

2. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

3. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин